**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**РУКОВОДИТЕЛЬ**
**Исполнительного комитета**
**Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**башкарма комитеты**
**ҖИТӘКЧЕСЕ**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

« 18 » 10 2018 ел № 309

«НГДУ Җәлилнефть» 12 ятмада скважиналар төзекләндерү. 2018 ел. 2 этап.» объекты өчен Азнакай муниципаль районы Әлкәй, Кәкре-Елга, Мәлбәгыш, Мәсгут авыл җирлекләре чикләрендә территорияне планныштыру һәм ызанлау проектын әзерләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы нигезендә, «Татнефть» ГАҖнең НГДУ «Җәлилнефть» тәкъдимен карап, Азнакай муниципаль районын территориаль планлаштыру схемасы нигезендә карар бирәм:

1. «НГДУ Җәлилнефть» 12 ятмада скважиналар төзекләндерү. 2018 ел. 2 этап.» объекты өчен Азнакай муниципаль районы Әлкәй, Кәкре-Елга, Мәлбәгыш, Мәсгут авыл җирлекләре чикләрендә территорияне планныштыру һәм ызанлау проектын «Татнефть» ГАҖнең НГДУ «Җәлилнефть» үз акчалары исәбеннән әзерләнү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2.Физик һәм юридик затларның территорияне планлаштыру документларының тәртибе, аларны әзерләү сроклары һәм эчтәлеге турында тәкъдимнәрен карау өчен Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының архитектура һәм инфраструктур үсеш бүлегенә җибәрергә. Территорияне планлаштыру документларын әзерләү һәм карап тоту сроклары турындагы тәкъдимнәрне караганда, әлеге тәкъдимнәрне кертkән физик һәм юридик затларны чакыруны тәэмин итәргә.

3.Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru//.

4.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура буенча урынбасары Р.Р.Ханнановка йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы - икътисад һәм финанслар буенча
җитәкче урынбасары Г.Г. Сөләйманова